КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 март г.Казань № 265

Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү өлешендә Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы үстерүне тәэмин итү мәсьәләләре буенча хокукый актлар проектларын әзерләү һәм кертү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары җитәкчеләренә Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү өлешендә Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы үстерүне тәэмин итү мәсьәләләре буенча хокукый актлар проектларын (алга таба – актлар проектлары), әгәр йөкләмәдә (күрсәтмәдә) аларның башка әзерләү сроклары каралмаган булса, тиешле йөкләмә (күрсәтмә) алынган вакыттан 24 сәгатьтән артмаган срокта (аларның ведомствоара килештерү вакытын кертеп) әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары җитәкчеләренә актлар проектлары кергән вакыттан иң күбе дүрт сәгать эчендә актлар проектларын килештерүне гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә – гамәлгә ашыругы тәкъдим итәргә. Әлеге срок узган очракта, акт проектын килештерелгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты бүлекчәләре җитәкчеләренә актлар проектлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кергән вакыттан алып 24 сәгатьтән дә артык булмаган срокта аларны эшләп бетерүне, килештерүне һәм имза куюга бирүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин